| МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.08.2016 ел № 21-74-38

Казан ш.

**2016 елда заказчы тарафыннан исәпләнелгән неустойкаларны (штрафлар, пенялар) гамәлдән алып ташлау тәртибе турында**

“2016 елда заказчы тарафыннан неустойкаларны (штрафлар, пенялар) түләүне кичектерү очраклары һәм кичектерүгә рөхсәт бирү тәртибе һәм (яки) исәпләнелгән неустойкалар (штрафлар, пенялар) суммаларын гамәлдән алып ташлау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәте карарының 5 пункты нигезендә, боерык бирәм:

2016 елда заказчы тарафыннан Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатыннан чыгып төзелгән контрактлар буенча исәпләнелгән неустойкаларны (пенялар, штрафлар) гамәлдән алып ташлау тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

**Министр** **Р.Р. Гайзатуллин**

Татарстан Республикасы Финанс
министрлыгының 02.08.2016 №21-74-38
боерыгы белән расланды

**2016 елда заказчы тарафыннан Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатыннан чыгып төзелгән контрактлар буенча исәпләнелгән неустойкаларны (пенялар, штрафлар) гамәлдән алып ташлау**
**Тәртибе**

1. Бу Тәртип, “Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында” 5 апрель, 2013 ел, № 44-ФЗ Федераль закон нигезендә, 2016 елда заказчы тарафыннан Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатыннан чыгып төзелгән контрактлар буенча исәпләнелгән неустойкаларны (пенялар, штрафлар) гамәлдән алып ташлау, бу Тәртипнең 2 пунктында күздә тотылган очракларда, кагыйдәләрен билгели.

2. Бурыч түбәндәге очракларда бу Тәртипкә туры китереп гамәлдән алып ташланырга тиеш:

а) түләнелмәгән бурыч контракт бәясенең 5 процентыннан артмаганда;

б) түләнелмәгән бурычның гомуми суммасы контракт бәясенең 5 процентыннан артып, әмма контракт бәясенең күбендә 20 процентын гына тәшкил иткәндә һәм 2016 ел азагына кадәр товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) бурычның 50 процентын түләгәндә.

3. Бурычны гамәлдән алып ташлау заказчының документлар белән расланган учет мәгълүматлары нигезендә хәл ителә. Заказчы бурычны гамәлдән алып ташлау максатыннан чыгып, товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) белән түләнелмәгән бурычны чагыштыруны тәэмин итә.

4.Контрактта күрсәтелгән яклар тарафыннан исәпләнеләгән һәм түләнелмәгән бурыч буенча расланган исәпләмәләр турында документ булганда, бурычны гамәлдән алып ташлау турында карар кабул итүгә нигез булып тора:

а) бу Тәртипнең 2 пунктындагы «а» пунктчасында күздә тотылган очракта – 2015 елда яки 2016 елда товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) тарафыннан контракт бурычларын (гарантия бурычларыннан тыш) тулы күләмендә үтәү, бу кабул итеп алу акты яки башка документ белән расланган булырга тиеш;

б) бу Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күздә тотылган очракта, нигезгә һәм бу пунктның «а» пунктчасында күздә тотылган документларга өстәмә рәвештә - товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) тарафыннан бурыч суммасын Таттарстан Республикасы бюджетына күчерү (бурыч дәүләт заказчысы алдында килеп чыккан очракта) турында Татарстан Республикасы бюджетының керемнәр администраторы мәгълүматы яки товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) тарафыннан түләнгән средстволарны заказчы счетына күчерү (бурыч дәүләт бюджеты, автоном учреждение, дәүләт унитар предприятиесе алдында килеп чыккан очракта) турында мәгълүмат.

Дәүләт заказчысы Татарстан Республикасы бюджетының керемнәр администраторының барлыкка килгән бурыч ягыннан дәүләт контракты буенча гражданлык-хокукый чаралар куллану вәкаләтләрен хәл итмәгән очракта, товар

җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) тарафыннан түләнгән бурыч суммаларын күчерү турында мәгълүмат, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең тиешле баш администраторының хокукый акты нигезендә билгеләнгән тәртиптә, тиешле вәкаләтләр бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре администраторы тарафыннан дәүләт заказчысына җибәрелә.

5. Товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) бурычның булуын расламаган очракта, аны гамәлдән алып ташлау турында карар кабул итәргә ярамый.

6. Заказчы, бу Тәртипнең 2 – 4 пунктларында күрсәтелгән нигезләр һәм документлар булганда, бурычны гамәлдән алып ташлау турында карар рәсмиләштерә һәм тиешле нигез килеп чыкканнан соң 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, товар җибәрүчегә (подрядчы, эш башкаручы), бу Тәртипкә кушымта нигезендәге форма буенча, аның күләмен күрсәтеп, исәпләнелгән һәм түләнелмәгән бурычны гамәлдән алып ташлау турында уведомление җибәрә.

7. Заказчы тарафыннан бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән уведомлениене формалаштыру “Мәгълүмат формалаштыру, шулай ук, заказчылар тарафыннан төзелгән контрактлар реестрын алып бару максатыннан чыгып, заказчы белән Федераль казначылык арасында мәгълүматлар һәм документлар алышу тәртибе турында” 24 ноябрь, 2014  ел, № 136н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы нигезендә контрактлар реестрына кертелгән мәгълүмат һәм документлар нигезендә хәл ителә.

8. Бурычны гамәлдән алып ташлау турында карар, комиссия тарафыннан, заказчының активлары керүгә һәм чыгуга карап кабул ителә һәм контрактлар реестрына кертелгән түләнелмәгән бурыч турында мәгълүматлардан һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 1 декабрь,  2010 ел, № 157н боерыгы белән расланган Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары, дәүләт фәннәр академияләре, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре өчен бухгалтерия учеты счетларының бердәм планын куллану буенча инструкциянең 7 пункты нигезендә, беренчел учет документларының мәҗбүри реквизитлары турында мәгълүматлардан торган, заказчының эчке боеру документы (боерык, күрсәтмә) белән рәсмиләштерелә.

9.  Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре администраторының дәүләт контракты буенча гражданлык-хокукый чаралар куллану вәкаләтләрен хәл итмәгән дәүләт заказчысы бурычны гамәлдән алып ташлаганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча бу Тәртипнең 4 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән Татарстан Республикасы бюджетының  керемнәр администраторына, гамәлдән алып ташланган бурыч суммасын һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының керемнәр классификациясе кодын күрсәтеп, бурычны гамәлдән алып ташлау турында мәгълүмат җибәрә.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 02.08.2016 №21-74-38 боерыгы белән расланган 2016 елда заказчы тарафыннан Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатыннан чыгып төзелгән контрактлар буенча исәпләнелгән неустойкаларны (пеняләр, штрафлар) гамәлдән алып ташлау тәртибенә кушымта

(Тәкъдим ителә торган үрнәк)

**Бурычлары (гарантия бурычларыннан тыш) 2015 елда яки 2016 елда товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) тарафыннан тулы күләмендә үтәлгән, Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатыннан чыгып төзелгән контрактлар буенча исәпләнелгән неустойкаларны (пеняләр, штрафлар) гамәлдән алып ташлау турында**

**уведомление № ____**

| | | | Кодлар |
|---|---|---|---|
| | «__» __________ 20__ ел | Дата | |
| Заказчы атамасы | ____________________ (тулы атамасы) | ИНН | |
| | ____________________ (кыскартылган атамасы) | КПП | |
| | | учетка кую датасы | |
| Заказчының оештыру-хокукый формасы атамасы | ____________________ | ОКОПФ буенча | |
| Заказчының урнашу урыны | ____________________ | ОКТМО буенча | |
| Товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) атамасы | ____________________ (юридик затның тулы атамасы/физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | ИНН | |
| | ____________________ (юридик затның кыскартылган атамасы | КПП | |
| | | учетка кую датасы | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Товар жибәрүченең (подрядчы, эш башкаручы) оештыру-хокукый формасы | ______________________ | ОКОПФ буенча | |
| Товар жибәрүченең (подрядчы, эш башкаручы) урнашу урыны | ______________________ | ОКТМО буенча | |
| | | ( ОКСМ буенча) | |

| | |
|---|---|
| Контракт номеры | |
| Контрактны төзү датасы | |
| Контрактлар реестрында реестр язуы номеры | |

Түбәндәге документ нигезендә_______________________________________________
(заказчының эчке боеру документы)

«__» __________ 20__ ел, № ___ заказчы түбәндәге суммада түләнелмәгән неустойкаларны (пенялар, штрафлар) гамәлдән алып ташлау турында хәбәр итә

_____________________________________________________________________________
(саннар белән һәм сүзләр белән күрсәтергә)

Заказчы җитәкчесе
(вәкаләтле заты) _________________ __________ _____________ __________
(вазыйфасы) (имзасы) (тулы имзасы)

«__»_______________ 20__ ел. М.У.